**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.08.2018 № 730

Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондын куллану һәм саклауны, әлеге фондның торак урыннары билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүен муниципаль контроль юлы белән гамәлгә ашыру буенча Административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Торак кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

2016 елның 14нче апрелендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 243 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондын куллану һәм саклауны, әлеге фондның торак урыннары билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүен муниципаль контроль юлы белән гамәлгә ашыру буенча Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3 пунктчасы белән тулыландырырга:

“3) керүче, аерым алганда, торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасы аша, гражданнарның муниципаль контроль органына мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрнең, юридик затларның, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүматлар,

муниципаль торак контроле органы тарафыннан белгеләнгән торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат:

- күп фатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналарны файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, хезмәтне туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре таләпләрен бозу фактлары турында;

торак ширкәте, торак милекчеләре, торак-төзелеш яки башка махсуслашкан кулланучылар кооперативы, яки башка махсуслашкан кулланучылар кооперативы булдыру тәртибенә, күпфатирлы йорт (алга таба - идарәче оешма) идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оештыру-хокукый формадан яки шәхси эшмәкәрдән бәйсез рәвештә юридик зат сайлап алуы турында күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең карар кабул итү тәртибенә таләпләрне бозу фактлары турында,

Россия Федерациясе Торак кодексының 164 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән затлар тарафыннан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару буенча килешү төзү турындагы карарны, шушы килешү һәм аларның нәтиҗәләре шартларын раслау тәртибен, күпфатирлы йортта бина милекчеләренең гомуми мөлкәтне тоту тәртибенә һәм әлеге йортта гомуми милекне агымдагы һәм капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыруны, Россия Федерациясе Торак кодексының 162 маддәсенең 2 өлешендә каралган йөкләмәләрне идарәче оешманың бозу очраклары турында, гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләүне кертү күләмен үзгәртү чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендә хокук бозу фактлары турында, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләр күрсәтүне) куллану нормативының билгеләнгән күләменең җирлексез фактлары турында, коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләр күрсәтүне) куллануның нормативлары составына таләпләрне бозуга, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр күрсәтү) куллану нормативларын билгеләү шартларын һәм методларын үтәмәүне;

- күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм тулай торакны тотуга түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу фактлары турында;

- социаль файдаланудагы наемга алынган йортларда торак биналарны вакытлыча куллануга биреп торучыларга һәм андый йортларда тулай торакларны вакытлыча куллануга алучыларга карата социаль файдалануда булган торак фондының торак биналарының найм килешүләрен төзүгә һәм үтәүгә мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлек алып баручы затлар тарафыннан, гражданнар тарафыннан, торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль

районы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары Глазков В.В.га йөкләргә.

Җитәкче Р. В. Михеев